ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 ноябрь 2016ел № 5770

«2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, Яр Чаллы шәһәренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыру максатында, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 450 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2017 ел – 150 мең сум, 2018 ел – 150 мең сум, 2019 ел – 150 мең сум.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 2 ноябрендәге
5770 номерлы карарына
кушымта

«2017-2019 елларга
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
кече һәм урта эшмәкәрлегенә
ярдәм күрсәтү һәм үстерү»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасы (алга таба-программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ санлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары:<br>Икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе<br>Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br>Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе<br>Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясен үстерү бүлеге |
| Программаның максаты | Эшмәкәрлекнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре тарафыннан җитештерелә торган продукция күләмендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештерә торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) өлешен арттыру өчен шартлар тудыру. |
| Программаның бурычлары | 1. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү өчен инфраструктураны үстерү.<br>2. Җитештерүне технологик яктан яңадан коралландыруга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга ярдәм итү.<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ каршылыкларны киметү. |

<table>
<tr><td></td><td>4. Кадрлар потенциалын үстерү.<br>5. Эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, иң яхшы практикаларны кертү, кооперацияне үстерү.<br>6. Мәгълүмати ярдәм.<br>7. Инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2017-2019 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><th>Финанслау чыганагы</th><th>2017 (мең сум)</th><th>2018 (мең сум)</th><th>2019 (мең сум)</th><th>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</th></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>150,0</td><td>150,0</td><td>150,0</td><td>450,0</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>150,0</td><td>150,0</td><td>150,0</td><td>450,0</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td>1) тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өлешен 32 % ка арттыру;<br>2) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын 4,7 %ка арттыру);<br>3) барлык предприятиеләр һәм оешмаларның исемлектәге уртача санында (ике урында эшләүчеләрдән башка) кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны өлешен (ике урында эшләүчеләрдән башка) 28,5% ка кадәр арттыру;<br>4) кече һәм урта эшмәкәрлектән шәһәр бюджетына салым түләүләре керүнең чагыштырма зурлыгын 36% ка кадәр арттыру</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td>Программаның үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Муниципаль программа хәл итәргә тиешле проблемаларның эчтәлеге

### Терминнар һәм билгеләмәләр

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – КУЭ субъектлары) - түбәндәге шартларга туры килә торган, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән кулланучылар кооперативлары һәм коммерция оешмалары (дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән

тыш), шулай ук шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген юридик зат оештырмыйча гына алып баручы физик затлар (алга таба - шәхси эшмәкәрләр), крестьян (фермер) хуҗалыклары:

1) юридик затлар өчен-Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр, чит ил юридик затлары, чит ил гражданнары, иҗтимагый һәм дини оешмалар (берләшмәләр), хәйрия һәм башка фондларның күрсәтелгән юридик затларның устав (җыелма) капиталында (пай фондында) катнашуының суммар өлеше егерме биш процenttан артмаска тиеш (акционерлык инвестиция фондлары һәм ябык пай инвестиция фондлары активларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булмаган бер яки берничә юридик затныкы булган катнашу өлеше егерме биш процenttан артмаска тиеш;

2) алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең уртача саны кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәр категориясе өчен хезмәткәрләрнең уртача санының түбәндәге чик күрсәткечләреннән артмаска тиеш:

а) урта предприятиеләр өчен йөз дә бер кешедән ике йөз иллегә кадәр;

б) кече предприятиеләр өчен йөз кешегә кадәр; кече предприятиеләр арасында микропредприятиеләр аерылып тора - унбиш кешегә кадәр;

3) өстәлгән кыйммәткә салымнан тыш товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатудан кергән табыш яки активларның баланс бәясе (төп акчаларның һәм материаль булмаган активларның калдык бәясе) алдагы календарь ел өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәр категориясе өчен билгеләнгән чик күрсәткечләреннән артмаска тиеш.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү - Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын үстерү буенча федераль программаларда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең төбәк программаларын һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең муниципаль программалары белән каралган чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлеге.

Административ каршылыклар - дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, контрольлек (күзәтчелек) итүче оешмалар һәм юридик затлар тарафыннан кылына торган законнарны бозучы гамәлләр, шулай ук хуҗалык эшчәнлеге өлкәсендә өстәмә һәм катлауландыручы процедуралар тудыра торган гамәлләр.

## Эшмәкәрлек торышының характеристикасы, проблемалар

Яр Чаллы – Татарстан Республикасы Кама аръягы регионының иң зур шәһәре, халык саны буенча икенче урында, халык саны ярты миллион кешедән артып китә.

Шәһәр югары үсеш алган социаль инфраструктурага, зур тарихи-мәдәни потенциалга ия.

Яр Чаллы шәһәре Татарстан Республикасының эре сәнәгать үзәге булып тора.

2015 ел өчен гомумреспублика күрсәткечләрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең өлеше

1 нче таблица

| Күрсәткечнең исеме | Гомумреспублика күрсәткечендәге өлеше, % |
|---|---|
| Халык саны | 14,0 |
| Икътисадый актив халыкның саны | 14,0 |
| Тулаем территориаль продуктның күләме | 9,6 |
| Үзебездә җитештерелгән, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләме | 10,5 |
| «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме | 12,4 |
| Ваклап сату әйләнеше | 16,6 |


2016 елның 1 гыйнварына салым исәбендә 19322 юридик зат һәм 15515 шәхси эшмәкәр тора.

2015 елда тулаем территориаль продуктта кече эшмәкәрлек субъектларының өлеше 30,5 % тәшкил итте.


2015 елда шәһәр бюджетына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан салым керемнәре өлеше - 32,0%.

Шәһәрнең кече предприятиеләрендә 44,5 мең кеше эшли, бу шәһәрдә эшләүчеләрнең исемлектәге уртача саныннан 25,2% тәшкил итә.

2015 елда эшчәнлек төрләре буенча
икътисадый актив кече һәм урта предприятиеләрне бүлү, %




2015 елда икътисадый эшчәнлек төрләре буенча
шәхси эшмәкәрләрне бүлү, %



Яр Чаллы шәһәрендә эшмәкәрлек өлкәсендә күпләп һәм ваклап сату оешмалары өлеше тигезлек хәленә китерелмәгән һәм югары булып тора. Бер үк вакытта производстволар булдыру һәм оештыру, социаль юнәлештәге хезмәтләр күрсәтү, түләүле хезмәт күрсәтү өлкәсендә объектлар булдыру һәм үстерү, энергияне сак тоту өлкәсендә эшчәнлек алып баручы инновацион предприятиеләр булдыру һәм аларны үстерү өлкәләрен үстерү таләп ителә.

Шәһәрдә эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасы булдырылган, ул 9 блоктан тора һәм төрле тармакларда кече һәм урта бизнеска ярдәм күрсәтүче 45 оешманы берләштерә.

Яр Чаллы шәһәрендә сәнәгать һәм индустриаль мәйданчыкларны үстерү дәвам итә, алар хәзер 4 - «Мастер» Кама индустриаль паркы», «Үсеш» сәнәгать паркы, «Чаллы» индустриаль паркы, «Җиһазлар базасы» сәнәгать мәйданчыгы.

«Яр Чаллы – тотрыклы үсеш шәһәре», «Яр Чаллы - Россия бизнес - мәгариф үзәге», «Эшмәкәрлек фабрикасы», «Эшмәкәрлек буенча кризиска каршы штаб» кебек шәһәр һәм республика проектлары гамәлгә ашырыла.

Эшмәкәрләрне республика һәм федераль финанс ярдәме программаларында катнашуга җәлеп итү буенча эш алып барыла. Консультация, хокукый ярдәм, шулай ук грантлар алуга документлар әзерләүдә ярдәм күрсәтелә.

Даими нигездә эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баруның аерым мәсьәләләренә багышланган һәм актуаль сораулар буенча фикер алышуга, шулай ук эшмәкәрлек өлкәсен алга таба үстерү өчен кумәк чаралар эшләүгә юнәлтелгән чаралар (киңәшмәләр, конференцияләр, форумнар, «түгәрәк өстәл» утырышлары һ.б.) үткәрелә.

Барлык чараларны яктырту өчен бизнеска ярдәм итүгә юнәлдерелгән массакүләм мәгълүмат чаралары булдырылган һәм эшли: "BusinessRepublic" эшлекле газетасы, «Business16.ru» порталы, www.chelny-invest.ru. инвестицияләр порталы.

Кече эшмәкәрлек субъектларының төп күрсәткечләре

2 нче таблица

| № т/б | Күрсәткечләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2015 ел хисап | 2016 ел бәя |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль берәмлектә исәпкә куелган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны | берәмлек | 28615 | 29730 |
| | алардан: | | | |

| № т/б | Күрсәткечләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2015 ел хисап | 2016 ел бәя |
|---|---|---|---|---|
| 1.1 | Кече һәм урта предприятиеләр саны (микропредприятиеләрне кертеп) | берәмлек | 13120 | 13720 |
| 1.2 | Шәхси эшмәкәрләрнең саны | кеше | 15515 | 16010 |
| 2 | Кече һәм урта предприятие хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны (ике урында эшләүчеләрдән башка), мең кеше | мең кеше | 49,4 | 50,2 |
| 3 | Кече предприятие хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы | сум | 24863,3 | 22330,8 |
| 4 | Кече (микроны кертеп) һәм урта предприятиеләрнең әйләнеше (гамәлдәге бәяләрдә) | млн. сум | 111211,9 | 118996,8 |
| 5 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының тулаем территориаль продукттагы (ТТП) өлеше | % | 30,5 | 31,0 |
| 6 | Кече һәм урта эшмәкәрлектән шәһәр бюджетына салым түләүләре керүнең чагыштырма зурлыгы | % | 32,0 | 35,0 |

Хәзерге вакытта кече һәм урта предприятиеләргә нәтиҗәле ярдәм күрсәтүдә каршылыкларның берсе булып аларның эшчәнлеген тәэмин итә торган инфраструктура объектларының булмавы яки җитмәве тора. Эре предприятиеләр үзләренә инфраструктураны үзләре тудыра: уку үзәкләре, маркетинг һәм юридик бүлекчәләр, коммуникацион инфраструктура - керү юллары, инженерлык челтәрләре һ.б., вәкиллекләр һәм кибетләр ачалар, үз банклары һәм хезмәткәрләре өчен социаль объектлар булдыралар.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары бу өлкәдә аеруча зыян күрә. Димәк, кече һәм урта предприятие җитәкчесе продукциянең уңышлы кокуренциясе өчен тәҗрибәле юристтан консультация алырга, маркетинг тикшеренүләре үткәрергә, товарны сату челтәре ярдәмендә сатарга тиеш.

Соңгы елларда кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасы объектлары барлыкка килүгә һәм гамәлдә булуга карамастан, киләчәктә аларны комплекслы үстерү өчен дәүләт һәм җирле хакимият органнарының ярдәме кирәк.

Эшмәкәрлек үсешен тоткарлый торган төп мәсьәләләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: югары квалификацияле кадрларга кытлык; кече һәм урта бизнес өчен салым йөкләнелеше югары дәрәҗәдә; финанс ресурсларының түбән дәрәҗәдә булуы; җир һәм күчемсез мөлкәтне сатып алу мөмкинлеге түбән булу; энергетика инфраструктурасыннан файдалану мөмкинлеге түбән булу; административ каршылыклар булу; яңа җиһазлар сатып алу белән бәйле проблемалар; кече һәм урта эшмәкәрлек

җитәкчеләренең һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокук, финанс, салым законнары мәсьәләләрендә белем дәрәҗәсе җитәрлек булмау.

Шунлыктан инде булган кече һәм урта бизнеска дәүләт ярдәменең төбәк системасы белән бәйләп, кече һәм урта эшмәкәрлеккә комплекслы муниципаль ярдәм күрсәтү системасын булдыру зарур.

Эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләсендә нәтиҗәле эзлекле сәясәт үткәрү, аның проблемаларын хәл итү икътисадны диверсификацияләүне үткәрергә, Яр Чаллы шәһәре өчен икътисадый үсешнең яңа хәрәкәт көчен булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Дөрес якын килгәндә, безнең сәнәгать предприятиеләре Россиянең башка җитештерүчеләренә лаеклы конкуренция тудыра ала. Әмма моның өчен дәүләт тарафыннан җитештерелә торган продукцияне яңа сату базарларына чыгару өлешендә ярдәм кирәк.

2017-2019 еллар чорына әлеге программаны эшләү һәм эшмәкәрлекне программа - максатчан ысул белән үстерү бурычларын хәл итү зарурлыгы берничә объектив факторга бәйле:

1) программаның максатларын һәм бурычларын Татарстан Республикасы норматив актларында билгеләнгән Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразлары һәм программалары, 2021 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеше стратегиясендә билгеләнгән өстенлекле бурычлар белән килештерү зарурлыгы;

2) Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган, кече һәм урта эшмәкәрлекне, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының аерым категорияләрен үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәте максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген билгеләү, әлеге чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм күләмен күрсәтеп, шулай ук программада катнашу өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары туры килергә тиешле критерийлар;

3) программа чаралары комплексын эшләү һәм гамәлгә ашыру максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек проблемаларының масштабы, катлаулылыгы һәм күптөрлелеге һәм аларны интеграцияләү зарурлыгы;

4) эшмәкәрләрнең проблемаларын хәл итү өчен төрле дәрәҗәдәге хакимият органнары һәм дәүләтнеке булмаган оешмалар, шул исәптән эшмәкәрләрнең иҗтимагый берләшмәләре тырышлыгын координацияләү ихтыяҗы;

5) Россия Федерациясенең төрле шәһәрләрендә кече эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча муниципаль максатчан программаларны гамәлгә ашыруда булган уңай тәҗрибә.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең эшмәкәрлеккә карата сәясәте кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә, яңа эш урыннары

булдыруга, яңа инновацион производстволарны үстерүгә, шәһәрнең инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген булдыруга юнәлдерелгән.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә бу мәсьәләләрне үз территориясендә финанс һәм башка ресурсларның минималь чыгымнары белән, шәһәрдә тотрыклылыкны саклап калуны һәм шәһәр халкының ихтыяҗларын бик яхшы канәгатьләндерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче сыйфат һәм сан нәтиҗәләре белән хәл итүне тәэмин итәргә кирәк.

## 3 бүлек. Программаның төп максаты һәм бурычлары

Яр Чаллы шәһәре икътисадының нигездә машина төзелеше предприятиеләренә таяна торган традицион структурасы шәһәр хуҗалыгының башка тармакларында кече һәм урта бизнес өлешен арттыру ягына үзгәртелергә тиеш. Икътисадның бу сегментлары яңа эш урыннары булдырырга һәм базарның гамәлдәге таләпләренә туры китереп товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр комплексын җитештереп, кулланучыларның шактый өлешенә хезмәт күрсәтергә тиеш. Кече һәм урта бизнес эре бизнес өчен кызыклы булмаган эшчәнлек өлкәләрендә үсәчәк, салым керемнәрен тотрыкландыруга ярдәм итәчәк, динамик рәвештә продукциянең яңа төрләрен һәм икътисадый нишаларны үзләштерәчәк.

Программаның максаты булып эшмәкәрлекнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре тарафыннан җитештерелә торган продукция күләмендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештерә торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) өлешен арттыру өчен шартлар тудыру тора.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге өстенлекле бурычларны хәл итәргә кирәк:

- кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктураны үстерү;
- җитештерүне технологик яктан яңадан коралландыруга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга ярдәм итү;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ каршылыкларны киметү;
- кадрлар потенциалын үстерү;
- эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, яхшы практикаларны куллану, кооперацияне үстерү;
- мәгълүмати ярдәм күрсәтү;
- инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

# 4 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

| Индикаторның исеме | Хисап формуласы | Күрсәткеч зурлыгы турында мәгълүмат чыганагы |
|---|---|---|
| Тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше), % | Формула таләп ителми. Мәгълүматлар социаль-икътисадый мониторинг буенча ТР комитеты тарафыннан бирелә | социаль- икътисадый мониторинг буенча ТР комитеты «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсе характеристикасы» |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше, берәмлек | Бер елга кече (микропредприятие), урта предприятиеләр һәм шәхси эшмәкәрләрнең саны суммасы | социаль- икътисадый мониторинг буенча ТР комитеты «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсе характеристикасы», Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым инспекциясе |
| Барлык предприятиеләр һәм оешмаларның исемлектәге уртача санында (ике урында эшләүчеләрдән башка) кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны өлеше, % | $Д = \frac{Пм+Пср}{Пкр+Пм} * 100\%$<br>где:<br>Пм- ) шәһәр кече предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны (ике урында эшләүчеләрдән тыш)<br>Пср- шәһәр урта предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны (ике урында эшләүчеләрдән тыш)<br>Пкр- шәһәр эре һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны (ике урында эшләүчеләрдән тыш) | социаль- икътисадый мониторинг буенча ТР комитеты;<br>«Кече һәм урта предприятиеләр һәм шәхси эшмәкәрләрне өйрәнүнең кайбер нәтиҗәләре» |

| Индикаторның исеме | Хисап формуласы | Күрсәткеч зурлыгы турында мәгълүмат чыганагы |
| --- | --- | --- |
| кече һәм урта эшмәкәрлектән шәһәр бюджетына салым түләүләре керүнең чагыштырма зурлыгы % | A/B *100%, где<br>А- кече эшмәкәрлектән шәһәр бюджетына салым түләүләре<br>В- шәһәр бюджетына салым түләүләре | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым инспекциясе |

# 5 бүлек. Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максат: эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерү өчен шартлар булдыру | | | | | | | | | | | |
| | | Тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше), % | | 31,0 | 31,5 | 31,8 | 32,0 | | | | |
| | | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә исәптә торучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, берәмлек | | 29730 | 30210 | 30640 | 31130 | | | | |
| | | Барлык предприятиеләр һәм оешмаларның исемлектәге уртача санында (ике урында эшләүчеләрдән тыш) кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны өлеше, % | | 28,1 | 28,2 | 28,4 | 28,5 | | | | |
| | | кече һәм урта эшмәкәрлектән шәһәр бюджетына салым түләүләре керүнең чагыштырма зурлыгы % | | 35,0 | 35,5 | 35,8 | 36,0 | | | | |
| 1 бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү | | | | | | | | | | | |
| Сәнәгать (индустриаль) парклары һәм сәнәгать мәйданчыкларын үстерү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Аккредитацияләнгән парклар саны, берәмлек | 4 | 5 | 6 | 7 | - | - | - | Барлыкка килгән эш урыннарының санын арттыру, салым түләүләрен арттыру |
| Күпфункцияле күргәзмә үзәген үстерүгә ярдәм итү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Күргәзмәләр саны, берәмлек | 25 | 30 | 30 | 30 | - | - | - | Шәһәрдә күргәзмә эшчәнлеген киңәйтү |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен муниципаль мөлкәт исемлеген төзү | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе | Ел саен | норматив-хокукый актлар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль мөлкәт бирү буенча тәкъдимнәр булу |
| 2 бурыч. Җитештерүне технологик яктан яңадан коралландыруга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга ярдәм итү | | | | | | | | | | | |
| Эшмәкәрләргә республика һәм федераль ярдәм программаларында катнашырга ярдәм итү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | консультация бирелгән УКП субъектлары саны | 1150 | 1050 | 1250 | 1400 | - | - | - | Яңа производстволар ачу, эш урыннары санын арттыру, салым түләүләрен арттыру |
| 3 бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ каршылыкларны киметү | | | | | | | | | | | |
| Эшмәкәрлек буенча кризиска каршы штаб утырышын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән утырышлар саны, берәмлек | 17 | 18 | 18 | 20 | - | - | - | Шәһәр дәрәҗәсендә эшмәкәрләрнең проектларын карау һәм ярдәм итү |
| Эшмәкәрләр ассоциациясен төзергә ярдәм итү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Яңа төзелгән ассоциацияләр саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | Гомуми мәсьәләләрне хәл итү өчен эшмәкәрләрне эшчәнлек төре буенча берләштерү |
| Шәһәр Хакиме каршындагы | Башкарма комитетның | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән утырышлар | - | 4 | 4 | 4 | - | - | - | Шәһәрдә инвестицион |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| эшмәкәрләрнең иҗтимагый советы утырышларын үткәрү | икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | | саны, берәмлек | | | | | | | | проектларны тормышка ашыру өчен муниципаль дәрәҗәдәге мәсьәләләрне хәл итү |
| Эшмәкәрлек инфраструктурасын барлыкка китерә торган оешмаларның утырышларын. очрашуларын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | Квартал саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | Эшмәкәрлек өлкәсендә коллегиаль системалы мәсьәләләрне хәл итү |
| 4 бурыч. кадрлар потенциалын үстерү | | | | | | | | | | | |
| «Яр Чаллы – бизнес-белем бирү үзәге» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Укучылар саны, кеше | 1600 | 1650 | 1700 | 1750 | - | - | - | Яңа эш башлаучы эшмәкәрләрнең эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару буенча белем дәрәҗәсен күтәрү һәм эшмәкәрләрнең гамәлдәге бизнесында карарлар кабул итү системасын камилләштерү |
| Сакчыл производствоны кертү буенча «Яр Чаллы – тотрыклы үсеш шәһәре»проектын тормышка ашыруда ярдәм итү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | проектта катнашучы предприятиеләр саны, берәмлек | 15 | 15 | - | - | - | - | - | Җитештерү чыгымнарын киметү, процессларны оптимизацияләү |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 5 бурыч. Эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, яхшы практикаларны куллану, кооперацияне үстерү | | | | | | | | | | | |
| Эшмәкәрләр съездын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 1 | - | 1 | - | - | - | Эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, гомумсистема мәсьәләләрен хәл итү |
| Җирле җитештерүчеләрнең продукциясен һәм хезмәтләрен тәкъдим итү буенча ярминкәләр, чаралар үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән ярминкәләр, чаралар саны, берәмлек | 5 | 10 | 10 | 10 | - | - | - | Җирле җитештерүчеләр продукциясен сату күләмнәрен арттыру |
| «Автокаланың яшь эшмәкәре» конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) | Яшьләр арасында нәтиҗәле тормыш стратегиясе буларак эшмәкәрлекне популярлаштыру |
| Эшмәкәрлек фабрикасы проектын тормышка ашыруда ярдәм итү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | проектта катнашучылар саны, кеше | 600 | 600 | 600 | 600 | - | - | - | Яшьләр арасында нәтиҗәле тормыш стратегиясе буларак эшмәкәрлекне популярлаштыру |
| 6 бурыч Мәгълүмати ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| «Кече һәм урта эшмәкәрлекнең бизнес | Башкарма комитетның | 2017-2019 еллар | порталга керүчеләр саны, | 500 | 2000 | 3000 | 4000 | - | - | - | Шәһәр икътисадының |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| навигаторы» мәгълүмат порталын тәкъдим итү | икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | | кеше | | | | | | | | реаль секторындагы агымдагы ихтыяҗлар турында эшмәкәрләрнең хәбәрдарлыгын арттыру |
| Эшмәкәрләрнең уңышлы эш тәҗрибәсен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | статьялар саны, данә | - | 20 | 20 | 20 | - | - | - | Уңышлы эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, бизнес белән идарә итүдә яңа алымнар һәм эшләнмәләр кертү |
| Эшмәкәрлек буенча мәгълүмат буклетлары, материаллар булдыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Эшмәкәрлек буенча эшләнгән мәгълүмат буклетлары, материаллар,данә | - | 500 | 500 | 500 | 50,0 (муниципаль бюджет) | 50,0 (муниципаль бюджет) | 50,0 (муниципаль бюджет) | Чараларда эшмәкәрләргә мәгълүмат бирү өчен басма тарату материалы булу |
| 7 бурыч. Инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | |
| Потенциаль инвесторлар белән инвестицияләр җәлеп итәргә ярдәм итүче презентация очрашулары үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән очрашулар саны, берәмлек | 10 | 15 | 15 | 15 | - | - | - | Конкурентлылыкка сәләтле производстволарга һәм эшчәнлек төрләренә инвестицияләр җәлеп итү |
| Яр Чаллы шәһәренең | Башкарма | 2017-2019 еллар | Инвестицияләр | 10 | 20 | 30 | 30 | - | - | - | Шәһәрдә |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| бердәм инвестицияләр каталогын алып бару | комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | | каталогына кертелгән проектлар саны, берәмлек, | | | | | | | | тормышка ашырырга әзер булган инвестиция проектлары булу |
| Программа буенча барлыгы:<br>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | | | | | 150,0 | 150,0 | 150,0 | |

## 6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Чыганаклар һәм чыгым юнәлешләре | Финанслау күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 450,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 |
| барлыгы | 450,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 |

## 7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын алга таба үстерү, кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсешен тоткарлый торган административ каршылыкларны бетерүгә юнәлдерелгән механизмнарны үстерү, шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлеге белән кызыксынуны арттыру хисабына халыкның эшлекле активлыгын үстерү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтүне камилләштерү тора.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова